ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ

предмет һәм методика өлкәсендәге КОМПЕТЕНЦИЯЛӘРЕН

бәяләү өчен биремнәр


ТАТАССР
Празднование 100-летия
Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең
100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020


ПОБЕДА!
1945–2020

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ ПРЕДМЕТ ҺӘМ МЕТОДИКА ӨЛКӘСЕНДӘГЕ КОМПЕТЕНЦИЯЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ӨЧЕН БИРЕМНӘР

КАЗАН
2020

ББК 74.202
Т 12

Под общей редакцией:
Нугумановой Л.Н., ректора, доктора педагогических наук
Яковенко Т. В., проректора по научной и инновационной деятельности, кандидата педагогических наук

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килешенеп,
Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының
Гыйльми советы карары нигезендә басыла

Рецензентлар:
Зиннатуллин Р.К., Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты; **Җамалетдинова З.И.,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты.
Төзүчеләр:
Шәмсетдинова Р.Р., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент;
Гыйлаҗева Л.Г., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты;
Фәттахова Р.Ф., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты;
Хадиева Г.В., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы.

Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының предмет һәм методика өлкәсендәге компетенцияләрен бәяләү өчен биремнәр/ төз.: Р.Р. Шәмсетдинова һ .б.— Казан: ТРМҮИ, 2020. —47 б.

Укытучыларны аттестацияләүнең региональ системасыннан бердәм федераль бәяләү материаллары (предмет һәм методик компетенцияләрне ачыклау) нигезендәге системага күчеше тормышка ашырылу стадиясендә. Әлеге кулланмада татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен федераль бәяләү материаллары таләпләренә туры китерелеп төзелгән биремнәр тәкъдим ителә.

©ТРМҮИ, 2020

ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ ПРЕДМЕТ ҺӘМ МЕТОДИК КОМПЕТЕНЦИЯСЕН БӘЯЛӘҮ ӨЧЕН БИРЕМНӘР

«Укытучы үзе укыган, өйрәнгән вакытта гына укыта. Укудан туктауга ул укытучы буларак яшәүдән туктый. Дөнья бер урында гына тормый, ул үсештә, үзгәрештә һәм , билгеле инде, педагогика да даими яңаруга, үзгәрүгә дучар»

К.Д. Ушинскийның әлеге сүзләре бүген аеруча актуаль. Укытучы профессиясе даими рәвештә үз өстеңдә эшләүне, белемнәрне яңартып торуны, заманча нәтиҗәле технологияләрне һәм ысулларны файдалануны таләп итә. Боларның барысына да бары тик өзлексез укыганда, квалификацияне күтәрү өстендә эшләгәндә генә ирешергә мөмкин. Мәгариф турындагы законның 48 маддәсе 1 бүлегендә педагогик хезмәткәрләрнең төп бурычларының берсе итеп “үзеңнең профессиональ дәрәҗәңне даими күтәрү” таләбе куелган.

Дәүләт, укытучының хәзерге җәмгыятьтәге ролен дөрес бәяләп, киләчәк мәктәбен формалаштыруда, педагог хезмәтенең иҗадилыгы өчен уңай шартлар тудыру, яшь буынны нәтиҗәле укыту һәм тәрбияләү юнәлешендә эзлекле адымнар ясый.

Укытучы үсешенең дәүләт системасын (НСУР) кертү - ул Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының өстенлекле юнәлешләренең берсе булып, гаять зур социаль һәм сәяси әһәмияткә ия проект булып тора.

Укытучы үсеше системасы педагогның һөнәри үсешен профстандарт таләпләренә туры китереп планлаштыра һәм педагогик белемне, шул исәптән, педагогик кадрларның өстәмә һөнәри белемнәрен яңартуны күз алдында тота.

Укытучы үсешенең дәүләт системасы үз эченә дүрт юнәлешне ала:

1. Педкадрларны аттестацияләүнең яңа моделе (әлеге модель педагогның предмет, методик, психолого-педагогик, коммуникатив компетентлыгын бердәм федераль бәяләү материаллары (ЕФОМ) нигезендә бәяләүне күз алдында тота).

2. Педагогның профессиональ үсешен, квалификациясен күтәрүне шәхси юнәлешле итеп оештыру, ягъни квалификация күтәрү курс алды бәяләү нәтиҗәләре нигезендә, укытучы шәхесенә юнәлдереп оештырылырга, квалификация күтәрү программасының нигезен 4 профессиональ компетенция булдыруга юнәлдерелгән бүлекләр тәшкил итәргә тиеш.

3. Мотивация, стимуллаштыру, бүләкләү (һөнәри конкурслар, укытучының һөнәри үсешенә юнәлдерелгән грантлар).

4. Педагогик кадрларны әзерләү (булачак педагогларны максатчан әзерләү, югары уку йортын тәмамлаучыларны шәхси якын килеп сертификацияләү.

Укытучыларны аттестацияләүнең региональ системасыннан бердәм федераль бәяләү материаллары (предмет һәм методик компетенцияләрне ачыклау) нигезендәге системага күчешен сынап карау 2015 елдан башланды һәм 2018 елда ТР сы бу системада беренчеләрдән булып Туган (татар) тел һәм әдәбият (татар әдәбияты буенча) катнашты.

Туган (татар) тел һәм әдәбият укытучыларының предмет һәм методик компетенцияләрен бәяләү өчен биремнәр ике бүлектә тәкъдим ителә. «Предмет компетентлыгы» бүлегендә татар теле һәм әдәбияты буенча тестлар тәкъдим ителә. «Методик компетентлык» бүлегендә исә татар телен һәм әдәбиятын укыту методикалары буенча төрле дәрәҗә катлаулылыктагы биремнәр китерелә. Бу өлеш бер яки берничә дөрес җавап вариантын сайлап ала торган, туры килүгә, эзлеклелеккә корылган ябык типтагы һәм кыска җаваплы ачык формадагы биремнәрне үз эченә ала.

Икенче өлеш педагогның предметны укыту методикасындагы компетентлыгын чагылдыруны таләп итә торган төрле дәрәҗә катлаулылыктагы 3 әр мәсьәләдән тора.

Беренче мәсьәләдә укытучының телне яки сөйләм төзелешен теге яки бу дәрәҗәдә өйрәнү методикасы принципларын белүен, бирелгән материалга анализ һәм теге яки бу тезисны аңлатуын, квалификацион осталыгын тикшерү максаты куела. Репродуктив һәм эзләнү характердагы эшчәнлек якынча 70%:30% чагыштырмасында.

Икенче мәсьәлә хаталарның нигезен һәм сәбәпләрен, укучыларның материалны үзләштерүдә туган кыенлыкларын ачуга, дидактик материалны дөресләү һәм/яки алар белән эш методикасын сайлый белү осталыгын ачыклауга юнәлдерелә. Репродуктив һәм эзләнү характердагы эшчәнлек якынча 30%:70% чагыштырмасында.

Өченче мәсьәлә уку процессы элементларын модельләштерүне, белем дәрәҗәләре, белемнәрне үзләштерү мөмкинлекләре төрле булган (аудиаль, визуаль, кинестетик) укучыларда (шул исәптән сәламәтлекләре чикле балаларда) авырлык тудырган очракларны искәртүне, белем бирүнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен заманча технологияләр һәм чаралар куллануны күздә тота. Репродуктив һәм эзләнү характердагы эшчәнлек якынча 15%:85% чагыштырмасында.

Профессиональ стандарт таләпләрен күздә тотып төзелгән укыту методикасы юнәлешендәге биремнәр укытучының гомумпедагогик һәм предмет компетентцияләре формалашу

дәрәҗәсенә бәя бирә. Аттестация узучы педагог, бирелгән биремнәрнең һәрберсен үтәп, төп белемнәргә, осталык һәм күнекмәләргә ия булуын чагылдыра алачак.

Методик әсбапта укытучыларга, бердәм бәяләү материалларын күз алдына китерү һәм әзерләнү өчен биремнәр тәкъдим ителә.

I.

1. Өрелмәле тартыклар төркемен билгеләгез

☐ [т], [г], [п]
☐ [җ], [һ], [с]
☐ [к], [ң], [х]
☐ [м], [р], [л]

2. Тәңгәллек урнаштырыгыз

1. Омонимнар	А. Яшь — карт
2. Синонимнар	Ә. (Печән) чаба — (тиз) чаба
3. Антонимнар	Б. Сөйкемле - мөлаем
4. Паронимнар	В. Болытлы (көн) - кояшлы (көн)
	Г. Тугры - туры
	Д. Орфоэпия — дөрес әйтелеш

3. Сүз ясалышы ысулы һәм сүз арасында тәңгәллек табыгыз

1. Кушымчалау	А. кайнар
2. Сүзләр кушылу	Ә. терекөмеш
3. Конверсия	Б. татарча
4. Сүзтезмәләр лексикалашу юлы	В. озынборын
	Г. хатын-кыз

4. Мөстәкыйль сүзләр генә булган төркемне күрсәтегез

☐ каен, зур, малай, бугай, әллә, ал
☐ турында, иң, чынлап, җырлап, әле
☐ кышкы, җыр, мин, ун, зур
☐ кием, әлбәттә, көчле, мөгаен, дөрес
☐ алтын, нур, мени, әле, урап

5. Бирелгән гади җөмләнең төрен билгеләгез

Елга ага — суын алып булмый. (Ә.)

☐ үтәүчесез җөмлә
☐ билгеле үтәүчеле фигыль җөмлә
☐ гомуми үтәүчеле фигыль җөмлә
☐ билгесез үтәүчеле фигыль җөмлә

6. Түбәндәге шигырь текстларында нинди троплар һәм сөйләм (стилистик) фигуралар кулланылган? Тәңгәллек урнаштырыгыз

1. Абый укуга китте, Әтиләр эшкә китте. Кайтам дип төшкә тикле, Әби кибеткә китте, — Кибеткә иткә китте. (*Р.Миңнуллин "Үзебез генә калгач")*	А. Антитеза
2. Таяк — таяк башында табак, Табак эчендә кибет, Кибет эчендә ике мең егет. *(Табышмак)*	Ә. Эпифора
3. Җырлый белмиләр бөркетләр, Сугыша белми былбыл, Җырдан сызланмый бөркетләр, Сугышта үлми былбыл. Муса кайсы шул кошларның? Җанына сыйган җир, күк… Сугыша белгән былбыл ул Һәм җырлый белгән бөркет. *(Зөлфәт)*	Б. Оксюморон
4. "Ирекле әсир"	В. Ялгау

7. Әдәби тел —

□ гомумхалык сөйләм теленең тел осталары тарафыннан эшкәртелгән, нормага салынган формасы;

□ билгеле бер телдә сөйләшүче кешеләрнең фикерне аңлаешлы итеп һәм гасырлар буена урнашып килгән таләпләрне бозмыйча, төгәл итеп сөйләү формасы;

□ язганда һәм сөйләгәндә алга куелган максатка ярашлы рәвештә тел-сурәтләү чараларыннан файдалану үзенчәлекләре.

□ төрле төбәкләрдә яшәп, төрле диалектларда сөйләшүче бер милләт кешеләре үзара аңлаша алырлык итеп эшкәртелгән һәм фәнни нормаларга салынган тел.

1.2. Татар әдәбияты

8. Әдәби төр буларак драмага хас билгене күрсәтегез:

1. вакыйга бер хикәяләүче аша гына сөйләнә
2. монолог һәм диалогларга корыла, искәрмәләр (ремаркалар) белән төзелә
3. лирик герой кичерешләре алгы планга куела
4. язучы вакыйгага һәм геройларга үз мөнәсәбәтен белдереп сурәтли

Җавап_____

9. Һәр җанрны үзе караган әдәби төр белән парлаштырыгыз:

1. Эпик	А. трагедия
2. Драма	Ә. баллада
3. Лирик	Б. хикәя
4. Лиро-эпик	В. шигырь

Җавап_____

10. Иҗат юнәлешләрен аерып күрсәтегез:

1. Гуманизм. 2. Футуризм. 3. Романтизм. 4. Мәхәббәт лирикасы. 5.Модернизм. 6. Реализм.

Җавап_____

11. Г. Тукайның "Исемдә калганнар әсәре:

1.тарихи роман
2. автобиографик повесть
3. сатирик поэма
4.фантастик хикәя

Җавап_____

12. Төшенчәләр һәм аңлатмалар арасында дөрес тәңгәллек урнаштырыгыз

1.Сюжет	А. әсәр өлешләренең урнашу тәртибе
2.Композиция	Ә.конфликтларның башлану ноктасы
3.Төенләнеш	Б. вакыйга-хәлләр яки кеше холкы-характерының үсү-үзгәрү тарихы

Җавап_____

13. Борынгы гомумтөрки әдәбиятка караган истәлекне билгеләгез

1. С. Сараи. Гөлстан бит-төрки
2. "Юрау китабы"
3. Хисам Кятиб. Җөмҗөмә солтан
4. "Идегәй" дастаны

Җавап_____

14. Пейзаж лирикасына караган әсәрне күрсәтегез

1. Г. Тукай. "Җәйге таң хатирәсе"
2. Һ. Такташ. "Мокамай"
3. М. Җәлил. "Җырларым"
4. Р. Харис. "Ак сөлге"

Җавап_____

Бүлек 2. Методик компетенция
Бүлек 2.1. Татар телен укыту методикасы

1. 15 (1). Татар теле грамматикасын укыту методикасының мөһим мәсьәләләренең берсе — фигыль формасын аның эчтәлегенә бәйле рәвештә өйрәтү. Әлеге принципның асылын аңлатыгыз, мисаллар китерегез.

16 (2). Яңа белем бирүдә яки аны ныгытуда түбәндәге бирем кулланыла ала: “Түбәндә китерелгән җөмләләрнең берсендә аерып куелган фигыль теләк мәгънәсен белдерми. Шул очракны табыгыз һәм теләк мәгънәсен белдерә торган итеп үзгәртегез”.

Җөмләләр:

1) Кемнән дә булса сорашып **беләсем килде**.

2) Яхшыга **булсын**, ходаем!

3) Еларга, еларга иде хәзер, күз яшьләрең дәрья булып бөтен хәсрәтеңне **алып китсен иде.**

4) Шул дәрьяда үзең дә йөзеп китеп, тыныч, кешесез **чыгыең.**

5) **Тизрәк кыймылдагыз, машиналар кузгалмасын.**

6) Эх, уйларны да, керләр кебек, ак иткәнче, пакъ иткәнче **чайкарга!**

Дөрес җавапны әйтегез һәм дәлилләгез. Укучының әлеге биремне чишкәндә күзәтелә торган типик хаталары нинди?

17 (3). Татар теле грамматикасын укыту методикасына һәм принципларына нигезләнеп, заманча укыту технологияләрен һәм системалы-эшчәнлекле юнәлешне кулланып, укучыларның әзерлек дәрәҗәсен, индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләрен истә тотып, сез татар телендә фигыль формасы белән эчтәлеге туры килмәгән очракны балаларга ничек аңлатырсыз?

2.2 Әдәбиятны укыту методикасы

Әдип, иманын барлагандай, һәр нәрсәне кабат күңеленнән кичерде: “Ык буйларының бу тирәсендә җир-суның, үсемлек һәм җәнлекләрнең шушы як табигатенә хас үзенчәлекләре сакланып калган. Мәгълүм булганча, бу төбәкнең ландшафты хакында рус язучысы Сергей Аксаков та игътибарга лаеклы истәлекләр язып калдырган. Шуларның һәммәсен искә алып, бу тирәне табигать һәйкәле итеп саклау турында хөкүмәт махсус карар чыгарды. Шулай булгач, кайбер кешеләрнең тугай белән чишмәләрне бозып ташлауларын берничек тә аклау мөмкин түгел. Гомер буе халык тормышында шатлыклы җыр булып яңгырап яшәгән көмештәй саф сулы чишмә ничек әле бүген генә, тормышлар җайга салынып

килгәндә генә, кирәкмәс булып чыксын икән?! Һич тә аңлашылмый.

Язучы буларак минем вазифам — туган-үскән якларның табигатенә карата менә шундый кансызлыкларны, салкын битарафлыкны, ваемсызлыкны фаш итү, халыкта табигатькә мәхәббәт уяту. Мин гаделлек өчен көрәшәм. Мин бу әсәремне хакыйкатьнең өстен чыгачагына ышанып, шуның белән рухланып язам. Әгәр дә шундый ышаныч канатландырып тормаса, минем язып утыруымның бер мәгънәсе дә калмас иде ...” (Г. Бәширов)

18 (1) Укытучы биргән сорауларның кайсысын проблемалы сорау дип саныйсыз:

1. Текстта язучы образы һәм хикәяләүче белән тәңгәл киләме?
2. Автор нинди символик образлар куллана?
3. Язучының халык алдындагы вазифасы нинди дип уйлыйсыз?
4. Әсәрнең авторын һәм исемен атагыз?

19 (2)

Укытучының табигатьне саклау һәркемнең бурычы дип саныйсызмы? — дигән соравына бер укучы: “Юк, табигатьне саклау безнең бурыч түгел, аның өчен махсус оешмалар бар,” — дип җавап бирә. Укучыларның бер төркеме аның белән килешүен белдерә. Укытучы бу очракта ни эшли:

1.Укучыны һәм теләктәшлек белдерүчеләрне бик каты кисәтә, алга таба бу фикерне исәпкә алмый гына дәресне дәвам итә.

2.Укучының хаксызлыгын бик күп мисаллар белән дәлилли, иптәшләреннән дә бу фикернең хата булуын дәлилләтә. Дәресен бу фикернең хата булуын раслауга багышлый.

3. Килеп туган каршылыклы фикердән проблемалы мәсьәлә тудырып аны уртага салып хәл итә һәм нәтиҗә ясыйлар.

20 (3)

Алда тасвирлаган ситуацияне хәл итү өчен проблемалы сорау тәкъдим итегез. Аның дәрес барышына тиешле юнәлеш бирерлек булуын дәлилләгез.

II.

Бүлек 1. Предмет компетенциясе
Бүлек 1.1. Татар теле

1. Ассимиляция — ... .

☐ төрле табигатьле авазларның бер-берсенә җайлануы
☐ тартыкларның төшеп калуы
☐ сузыклар өстәлү
☐ авазларның бер-берсенә охшашлануы

2. Тәңгәллек урнаштырыгыз.

1. Күз ачып йомганчы	А. Үчле булу
2. Куенында таш саклау	Ә. Бик күп
3. Телне йотарлык	Б. Бик тиз
4. Тавык чүпләп бетерерлек түгел	В. Бик тәмле

3. *Җанына* сүзен морфемаларга бүлүнең дөрес вариантын күрсәтегез.

☐ җаны- н – а
☐ җанын – а
☐ җан – ы –на
☐ җан – ын – а

4. Сөйләүче үзе катнашмаган, күрмәгән, яисә анык белмәгән эш, хәл, хәрәкәт турында бары аның нәтиҗәсе буенча яки башка чыганакларга таянып хәбәр иткәндә кулланыла торган форманы күрсәтегез

☐ билгеле үткән заман хикәя фигыль
☐ кабатлаулы үткән заман хикәя фигыль
☐ күптән үткән заман хикәя фигыль
☐ билгесез үткән заман хикәя фигыль

5. Бирелгән гади җөмләнең төрен билгеләгез
И кызым...

☐ атау җөмлә
☐ мөрәҗәгать җөмлә
☐ исем җөмлә
☐ сүз җөмлә

6. Тәңгәллек урнаштырыгыз

1. Кабатлау	А. Бер үк сүзләр, авазлар, сүзтезмәләрнең шигырь юлы башында кабатлануы

2. Анафора	Ә. мәгънә ягыннан якын торган сүзләр яки сүзтезмәләрнең, бер-бер артлы тезелеп килеп, яңгырашны көчәйтүе яисә көчсезләндерүе
3. Градация	Б. бер-берсенә тиңдәш синтаксик конструкцияләрнең яки тезмәләрнең янәшә куелуы
4. Янәшәлек	В. әсәр эчендә сүзләрнең кабатлануы

7. Плеоназм күренешенә караган очракны күрсәтегез

□ Бу сорау шәхсән мине бик борчый.

□ Хатынның йөзе кинәт бозылды.

□ Юл буена тезелгән кашкарыйлар, лаләләр каршы ала сине.

□ Матур кыз матур яза.

1.2. Татар әдәбияты

8. Әдәби төр буларак эпик әсәргә хас билгене күрсәтегез:

1. вакыйганы хикәяләүче үзе күргәннәрне генә сөйләп чыга
2. сәхнә өчен иҗат ителә
3. сюжетлылык хас
4. лирик “мин” исеменнән сөйләнелә

Җавап_____

9. Һәр жанрны үзе караган әдәби төр белән парлаштырыгыз:

1.Эпик	А. комедия
2. Драма	Ә. поэма
3. Лирик	Б. повесть
4.Лиро-эпик	В. җыр

Җавап_____

10. Иҗат юнәлешләрен аерып күрсәтегез:

1. Модернизм. 2. Авангардизм. 3. Романтизм. 4. Реализм. 5. Гуманизм. 6. Сәяси лирика.

Җавап_____

11. Г. Ахуновның “Идел кызы” әсәре:

1. роман
2. повесть
3. шигъри роман
4.фантастик бәян

Җавап_____

12. Әдәби юнәлешләр үсешенең эзлеклеген чагылдырыгыз.

А. Пролог	1. хикәяләүнең иң кечкенә мәгънәви кисәге; геройның эш-хәрәкәтләренә этәргеч булган сәбәп.
Ә. Идея	2.әсәрдәге конкрет вакыйгалар һәм образлар аша бирелгән төп фикер. Тема куйган мәсьәләнең җавабы.
Б. Мотив	3. әдәби әсәрнең кереш өлеше.

Җавап_____

13. XX гасыр башында иҗат иткән шагыйрьне билгеләгез
1. Ибраһим Гази
2. Фирдәүси
3. Сәгыйть Рәмиев
4. Рабит Батулла
Җавап_____

14. Тарихи әсәрне күрсәтегез
1. Ә. Еники. “Матурлык”
2. Н. Фәттах. “Сызгыра торган уклар”
3. Т. Миңнуллин. “Миләүшәнең туган көне”
4. Р. Харис. “Исемсезләр”
Җавап_____

16.

(1). Татар теле грамматикасын укыту методикасының мөһим һәм катлаулы мәсьәләләренең берсе — бер составлы җөмләләрнең төрен билгеләү. Әлеге грамматик очракның асылын аңлатыгыз, мисаллар китерегез.

17 (2). Яңа белем бирүдә яки аны ныгытуда түбәндәге бирем кулланыла ала: “Түбәндә китерелгән бер составлы фигыль җөмләләрнең берсенең төре дөрес күрсәтелмәгән, шул очракны табыгыз һәм җавапның дөрес вариантын языгыз”.

Җөмләләр:

1. Икебез ике илләрдә аерым гомер ителә. — *Билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә.*

2. Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар. - *Билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә.*

3. Чишмәне таш белән әйләндерәләр. — *Билгесез үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә.*

4. Кыскасы, чигенеп булмый иде инде. — *Гомуми үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә.*

Таңнар ата, өзелә үзәк, уйната да елата.- *Үтәүчесез бер составлы фигыль җөмлә.*

Тәрәзә яңакларында — кызыл башлы озын сөлгеләр, кашагада — ак челтәрләр... — *Бер составлы исем җөмлә.*

Дөрес җавапны әйтегез һәм дәлилләгез. Укучының әлеге биремне чишкәндә күзәтелә торган типик хаталары нинди?

18 (3). Татар теле грамматикасын укыту методикасына һәм принципларына нигезләнеп, заманча укыту технологияләрен һәм системалы-эшчәнлекле юнәлешне кулланып, укучыларның әзерлек дәрәҗәсен, индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләрен истә тотып, сез татар телендә бер составлы җөмлә төрләренә хас үзенчәлекләр турында белемнәрне балаларга ничек җиткерерсез?

2.2 Әдәбиятны укыту методикасы

"Безнең телебез — бик моңлы тел", ди халык. Шушы моң халыкның хәтер кылларна кагыла да үткәннәрне бүгенге белән тоташтыра.

Телнең сыгылмалылыгы, матурлыгы, моңлылыгы, композиторлар, шагыйрьләр өчен генә түгел, ул барыбыз өчен дә кирәк. Матур итеп сөйләшә белгән кеше генә матур итеп уйлый белә, матур итеп уйлый белгән кеше матур эшләргә омтыла.

Әйе, күңел байлыгы җаныбызга телебез аша туплана. Әгәр син уз телеңне белмисең икән, үз халкыңның мәдәниятен, рухи байлыгын үзләштерә алмыйсың. Әгәр без халкыбызның гасырлар буе туплап килгән рухи байлыгын аңларга, үзләштерергә телибез икән, иң беренче туган телебезне белергә тиешбез.

Туган телеңне белмәү — наданлык. Бу нәрсә, минемчә, телгә һәм үз халкыңа мәхәббәт булмаудан килеп чыга.

Тел — халык күңеленең кыңгыравы. Ә кыңгырау — кагылмасаң чыңламый. Әйдәгез, шушы кыңгырауны ешрак кагыйк. Ул туктамасын, тавышы гел саф булсын, аның моңы еракка яңгырасын. (Ф. Яруллин)

19 (1) Укытучы биргән сорауларның кайсысын проблемалы сорау дип саныйсыз:

1.Текст нәрсә турында?

2. Автор символик образлар кулланамы?

3. Рухи хәзинә төшенчәсен ничек аңлыйсыз?

4. Туган телеңне белмәү — наданлык. Сез моның белән килешәсезме?

20 (2)

Укытучының: "Туган телне белмәү чыннан да наданлык дип саныйсызмы? — дигән соравына бер укучы: "Юк, туган телне

белмәгән килеш тә белемле булырга мөмкин,” — дип җавап бирә. Укучыларның бер төркеме аның белән килешүен белдерә. Укытучы бу очракта ни эшли:

1.Укучыны һәм теләктәшлек белдерүчеләрне бик каты кисәтә, алга таба бу фикерне исәпкә алмый гына дәресне дәвам итә.

2. Килеп туган каршылыклы фикердән проблемалы мәсьәлә тудырып аны уртага салып хәл итә һәм нәтиҗә ясыйлар.

3. Укучының хаксызлыгын бик күп мисаллар белән дәлилли, иптәшләреннән дә бу фикернең хата булуын дәлилләтә. Дәресен бу фикернең хата булуын раслауга багышлый.

21 (3)

Алда тасвирлаган ситуацияне хәл итү өчен проблемалы сорау тәкъдим итегез. Аның дәрес барышына тиешле юнәлеш бирерлек булуын дәлилләгез.

III.

Бүлек 1. Предмет компетенциясе
Бүлек 1.1. Татар теле

1. Алгы рәт сузыклары гына булган төркемне билгеләгез

☐ [у], [и], [о], [а]
☐ [ө], [ә], [ү], [и]
☐ [ә], [а], [ы], [и]
☐ [ә], [а], [ы], [и]

2. Метафоралардан гына торган рәтне билгеләгез

☐ күз алмасы, зал елый, татар йоклый
☐ хисап тотты, Сәйдәшне тыңлыйм, кара кайгы
☐ көмеш тавыш, сәгать йөри, ут толымнары
☐ тимер юл, баш кату, хисап тотты

3. *Балакай, бәләкәй, дәү, тау, хикәят, әкият* сүзләре сүз ясалышының кайсы ысулы белән ясалган?

☐ сүзләрне кушу юлы белән
☐ сүз ясагыч кушымчалар ялгау юлы белән
☐ бер сүз төркеменнән икенчесенә күчү юлы белән
☐ сүзләрнең аваз составын үзгәртү юлы белән

4. Билгенең билгесен белдереп килә торган сүз төркемен күрсәтегез

☐ сыйфат

□ рәвеш
□ сыйфат фигыль
□ хәл

5. Катлаулы кушма җөмлә ничә компоненттан тора?

Азмы, күпме вакыт үткәндер, бик каты ишек дөбердәтүгә Садыйк уянып китте, ул арада булмады, түрдә әнисе ут алды, ишек ачылды, тыштан әллә никадәр стражниклар белән бергә үрәтник килеп керде. (Г. Исхакый)

□ 4
□ 5
□ 7
□ 6

6. Тәңгәллек урнаштырыгыз

1. Кабатлау	А. Күрмимен алны вә артны, и чабам мин, и чабам; Ашыгам, тирлим, пешәм һәм кып-кызу уттай янам. (Г. Тукай)
2. Анафора	Ә. Алсу чәчәк, зәңгәр букет, Дустым, сиңа бүләгем. Күрмә михнәт, яшә рәхәт, Дустым, сиңа теләгем. (Халык җыры)
3. Градация	Б. Су анасыннан котылгачтын, тынычлангач, әни И орышты, и орышты, и орышты соң мине. (Г. Тукай)
4. Янәшәлек	В. Бер җирдә юк андый ак каеннар, Бер җирдә юк андый урманнар, Бер җирдә юк камыш сабаклары — Андагыдай шаулый торганнар. (Һ. Такташ)

7. Кайсы җөмләдә стилистик хата бар?

□ Иң беренче булып килим диеп,
Өскә матур яңа күлмәк киеп…
□ Башкаланың үзәген сылу йортлар били.
□ Чибәр кызлар суга бара.
□ “Иң сөйкемле егет” номинациясендә җиңеп чыкты.

1.2. Татар әдәбияты

9. Әдәби төр буларак лирика хас билгене күрсәтегез:

1. хикәяләүченең лирик чигенешләренә нигезләнә
2. монолог һәм диалогларга корыла
3. лирик герой кичерешләре алгы планга куела
4. сюжетлылык хас

Җавап_____

10. Һәр җанрны үзе караган әдәби төр белән парлаштырыгыз:

1.Эпик	А. трагедия
2. Драма	Ә.баллада
3. Лирик	Б. повесть
4.Лиро-эпик	В. шигырь

Җавап_____

11. Иҗат юнәлешләрен аерып күрсәтегез:
1. Романтизм. 2. Драматизм. 3. Гуманизм. 4.Классицизм. 5. Модернизм. 6. Реализм.
Җавап_____

12. Фәнис Яруллинның “Җилкәннәр җилдә сынала”әсәре:
1.тарихи драма
2. автобиографик повесть
3. детектив повесть
4. тарихи биографик хикәя
Җавап_____

13. Төшенчәләр һәм аңлатмалар арасында дөрес тәңгәллек урнаштырыгыз

1. Мәдхия	А. вафат булган кешеләрне, гадәттә,күренекле затларны мактау, олылап искә алу шигыре.
2. Нәзыйрә	Ә. мактау эчтәлегендәге лирик шигырь
3. Мәрсия	Б. башка бер авторның теге яки бу әсәре тәэсирендә туган, аңа охшатып язылган әсәр.

Җавап_____

14. Мәгърифәтчелек методы белән иҗат ителгән әсәрне билгеләгез
1. Шәриф Хөсәенов. “Зөбәйдә — адәм баласы”
2. Нурихан Фәттах “Итил суы ака торур”
3. Мөхәммәт Мәһдиев. “Бәхилләшү”
4. Муса Акъегет. “Хисаметдин менла” дастаны
Җавап_____

15. Лиро-эпик төргә караган әсәрне күрсәтегез
1. Г. Тукай. “Җәйге таң хатирәсе”
2. Һ. Такташ. “Мокамай”
3. М. Җәлил. “Җырларым”
4. Р. Харис. “Ак сөлге”
Җавап_____

Бүлек 2. Методик компетенция
Бүлек 2.1. Татар телен укыту методикасы

16 (1). Татар теле грамматикасын укыту методикасының мөһим мәсьәләләренең берсе — ия белән хәбәр арасында тыныш билгесен дөрес куярга өйрәтү. Әлеге грамматик очракның асылын аңлатыгыз, мисаллар китерегез.

17 (2). Яңа белем бирүдә яки аны ныгытуда түбәндәге бирем кулланыла ала: “Түбәндә китерелгән җөмләләрнең берсендә ия белән хәбәр арасында тыныш билгесе дөрес куелмаган, шул очракны табыгыз, хатаны төзәтегез”.

Җөмләләр:

1) Халыкны халык иткән, дөньяга таныткан сыйфат - аның күңел байлыгы, теле, сәнгате.

2) Табигатьне танып белү һәм табигать белән татулыкта яшәү — кеше өчен бәхет.

3) Тел ул — халыкның рухи дәвасы.

4) Шигърият — үзе җыр ул.

5) Әтиемнең иң олы апасы — бу.

6) Кеше күңеленең иң югары ноктасы — кешене ярату ул.

Дөрес җавапны әйтегез һәм дәлилләгез. Укучының әлеге биремне чишкәндә күзәтелә торган типик хаталары нинди?

18 (3). Татар теле грамматикасын укыту методикасына һәм принципларына нигезләнеп, заманча укыту технологияләрен һәм системалы-эшчәнлекле юнәлешне кулланып, укучыларның әзерлек дәрәҗәсен, индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләрен истә тотып, сез татар телендә ия белән хәбәр арасында тыныш билгесенең дөрес куелышы турында белемнәрне балаларга ничек җиткерерсез?

2.2 Әдәбиятны укыту методикасы

Тышта ай яктысы, көнчыгыш ягыннан йомшак кына салкын җил исә иде. Ерак-еракларга җәелеп киткән газамәтле диңгез ай яктысында аклы-күкле ялтырап, очсыз-кырыйсыз нур һәм серле күләгәләр эчендә гүя күңелсез генә көлемсерәп ята иде... Аның кырыенда гына караңгы баракларда салам өстенә түшәлеп яткан адәм балалары күбрәк балык тотып, аена кырыгар сум акча эшләү өмете белән, һәм дә әллә кайларда, зиннәтле бүлмәләрдә йомшак түшәкләр өстендә сузылып яткан промысло хуҗалары шул ук балык хисабына кырыгар мең сум төшерү хыялы белән ләззәтләнеп төш күрә-күрә йоклаган чагында, табигатьнең матур һәм аңгыра

мәхлуклары — балыклар, һичнәрсәдән хәбәрсез, бертуктамый айга каршы сикерә, уйный иделәр… (Ш. Камал)

19 (1) Укытучы биргән сорауларның кайсысын проблемалы сорау дип саныйсыз:

1.Табигать бирелеше сезгә охшадымы?

2. Кешеләрнең дөньяга карашлары төрле. Бу мөнәсәбәтләрдә катлаулылык тудырамы? Фикерегезне дәлилләгез.

3. Өзектә символлар бармы?

4. Әсәрнең авторын һәм исемен атагыз?

20 (2) Укытучының "Һәркемнең үз фикере булырга тиешме?" — дигән соравына бер укучы: "Бу тормышта катлаулылык тудыра," — дип җавап бирә. Укучыларның бер төркеме аның белән килешүен белдерә. Укытучы бу очракта ни эшли:

1. Килеп туган каршылыклы фикердән проблемалы мәсьәлә тудырып аны уртага салып хәл итә һәм нәтиҗә ясыйлар.

2. Укучының хаксызлыгын бик күп мисаллар белән дәлилли, иптәшләреннән дә бу фикернең хата булуын дәлилләтә. Дәресен бу фикернең хата булуын раслауга багышлый.

3. Укучыны һәм теләктәшлек белдерүчеләрне бик каты кисәтә, алга таба бу фикерне исәпкә алмый гына дәресне дәвам итә.

21 (3)

Алда тасвирлаган ситуацияне хәл итү өчен проблемалы сорау тәкъдим итегез. Аның дәрес барышына тиешле юнәлеш бирерлек булуын дәлилләгез.

IV.

Бүлек 1. Предмет компетенциясе

Бүлек 1.1. Татар теле

1. Сузык авазларның дифференциаль билгеләре буенча сүзне табып билгеләгез: 1нче сузык: арткы рәт сузыгы, иренләшкән; 2нче сузык: арткы рәт, урта күтәрелеш, кыска сузык аваз

☐ утын

☐ үлән

☐ урам

☐ үрнәк

2. *Кызыл кара, ак кер, кара аккош* мисаллары тел гыйлемендәге … күренешен чагылдыралар.

☐ синекдоха

☐ омоформа

☐ метонимия

☐ катахреза

3. Тамыр дөрес күрсәтелмәгән төркемне күрсәтегез

□ котлау (кот-)
□ ямьле (ямь-)
□ башлангыч (башла -)
□ рухлану (рух-)

4. Өченче төр хәл фигыльдән торган рәтне билгеләгез

□ калгач, очрагач, ияргәч, сөйләгәч
□ уйлый-уйлый, сөйләшә-сөйләшә, ала-ала, сыйлый-сыйлый
□ караганчы, тыңлаганчы, күргәнче, танышканчы
□ йөрүче, аңлаучы, сөйли торган, белә торган

5. Иярчен ия җөмләне билгеләгез

□ Дөнья өчен эшләсәң, шул — яшәвең кадере. (М)
□ Учагы нинди, ялкыны шундый. (М)
□ Егет шул егет була: каравында өмет була. (М)
□ Күрә: дөньялар үзгәреп килә. (М)

6. Тәңгәллек урнаштырыгыз

1. Риторик эндәшү	А. Кемгәдер, нәрсәгәдер мөрәҗәгать итеп сөйләү
2. Риторик сорау	Ә. Капма-каршы куелу
3. Оксюморон	Б. Хис-тойгы каршылыгы
4. Антитеза	В. Кемгәдер, нәрсәгәдер раслауны белдергән сорау белән мөрәҗәгать итү

7. Кайсы сүзтезмәдә стилистик хата бар?

□ беренче урын
□ беренче дебюты
□ беренчедән башлау
□ беренче тапкыр күрү

1.2. Татар әдәбияты

9. Лиро-эпик төргә хас билгене күрсәтегез:

1. күптән булып узган вакыйга сөйләнә
2. монологка корыла, хис-кичерешләр өстенлек итә.
3. медитативлык хас, тоташ сюжетка корылмый, лирик герой кичерешләре алгы планга куела.
4. хикәяләү, сюжетлылык, лирик герой образы, хис-кичерешләр тирәнлеге тезмә формага салып бирелә

Җавап_____

10. Һәр әсәрне үзе караган җанр белән парлаштырыгыз:

1.Г. Тукай. “Туган тел”	А. трагедия
2. Н. Фәттах “Кол Гали	Ә.баллада
3. М. Җәлил “Сандугач һәм чишмә”	Б. хикәя
4. Ә. Еники “Матурлык”	В. шигырь

Җавап_____

11. Иҗат юнәлешләрен аерып күрсәтегез:
1. Романтизм. 2. Футуризм. 3. Сюрреализм. 4. Модернизм 5.Нигилизм. 6. Реализм.
Җавап_____

12. М. Фәйзинең “Галиябану” әсәре:
1. драма
2. музыкаль драма
3. трагедия
4. трагикомедия
Җавап_____

13. Төшенчәләр һәм аңлатмалар арасында дөрес тәңгәллек урнаштырыгыз

1. Реализм	А. тормышны рухи дөнья, уй-фикер, хис-кичереш, мөнәсәбәт, тәэсир көзгесендә чагылышын күрсәтү, күп катламлы тормыш моделен төзү.
2. Модернизм	Ә.билгеле бер идеал яктылыгында тормышны үзгәртеп тасвирлау.Хыял-идеалдагыча яшәеш рәвешен күрсәтергә омтылу, ике катламлы томыш моделе төзү.
3. Романтизм	Б. тормышны үз формасында күрсәтү, бер катламлы тормыш моделе төзү

Җавап_____

14. Романтизм юнәлешендә иҗат ителгән әсәрне билгеләгез
1. Г. Гыйльманов. “Албастылар”
2. Г. Камал. “Бүләк өчен”
3. Г. Исхакый. “Өч хатын белән тормыш”
4. Г. Ибраһимов “Яшь йөрәкләр”
Җавап_____

15. Туган як, Ватан төп мотив булган эсәрләрне билгеләгез
1. Г. Тукай. “Пар ат”

2. Дәрдемәнд. “Видагъ”
3. М. Җәлил. “Дару”
4. Р. Фәйзуллин. “Җаныңның ваклыгын...”
Җавап_____

Бүлек 2. Методик компетенция
Бүлек 2.1. Татар телен укыту методикасы

16 (1). Татар теле грамматикасын укыту методикасының мөһим мәсьәләләренең берсе — кушма җөмлә төрләрен өйрәтү. Әлеге грамматик очракның асылын аңлатыгыз, мисаллар ярдәмендә нигезләгез.

17 (2). Яңа белем бирүдә яки аны ныгытуда түбәндәге бирем кулланыла ала: “Түбәндә китерелгән кушма җөмләләрнең берсенең төре дөрес билгеләнмәгән, шуны табыгыз һәм хатаны төзәтегез”.

Җөмләләр:

1) Ә без тарихны нибары сугыш — кырык беренче елгы сугыш- башланган көннән генә башлана дип уйлый идек. — *Иярчен аергыч җөмлә*

2) Бәхетне байлык, муллык, югары белем, хыялый дөнья гына алып килми икән шул. — *Тиңдәш кисәкләр белән катлауландырылган гади җөмлә*

3) Туышы яман туганын яманлар. — *Синтетик иярчен ия җөмлә*

4) Асылы нинди, нәселе шундый. — *Аналитик иярчен хәбәр җөмлә*

5) Тел әйтә алмаганны җыр әйтер. — *Синтетик иярчен тәмамлык җөмлә*

6) Бәхете бар икән малайның: әнисеннән хат килде. — *Иярчен аныклагыч җөмлә*

Дөрес җавапны әйтегез һәм дәлилләгез. Укучының әлеге биремне үтәгәндә күзәтелә торган типик хаталары нинди?

18 (3). Татар теле грамматикасын укыту методикасына һәм принципларына нигезләнеп, заманча укыту технологияләрен һәм системалы-эшчәнлекле юнәлешне кулланып, шулай ук укучыларның әзерлек дәрәҗәсен, индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләрен истә тотып, сез татар телендә кушма җөмлә төрләре турында белемнәрне балаларга ничек җиткерерсез?

2.2 Әдәбиятны укыту методикасы

Инде яз да килеп җитте. Иге-чиге булмаган күктән кояш иртәдән кичкә кадәр җир йөзенә үзенең якты нурларын чәчә, бакчалар, болыннарны томалаган үләннәрне иркәләп үстерә. Бакчадагы гөлләр, кырдагы игеннәр аның җылы нурлары астында көннән-көн матурлана баралар.

Табигать нәрсәгә алай гөр килә? Матур агач яфраклары иртә белән, кояш чыкканда елмая-елмая бер-берсенә нәрсә сөйлиләр? Тау башында чылтырап аккан чишмәләр, елгалар шулкадәр ашыгып кемгә нинди шатлыклы хәбәр илтәләр дә болыннардагы үләннәр белән урманнардагы миләүшә чәчәкләре, кырдагы игеннәр нәрсә турында киңәшәләр? Табигать нәрсә сөйли?

Без чәчәк атыйк һәм шәфкатьле кояш астында орлыкларыбыз тәмам өлгереп җиткәч, аларны ераккa-ераккa, бөтен дөньяга таратыйк. Бөтен җирдә безнең балаларыбыз үссеннәр. Алар дөньяда шат яшәп, безнең төсле алар да, көчләре җиткән кадәр башкаларга файда китерсеннәр. Җир йөзендә безнең нәселебез никадәр күп үрчесә, шулкадәр адәм балаларына сулыш алу иркен, яшәү дә уңай һәм күңелле булыр. Туганнар, тизрәк, тизрәк яфрак ярып бетерергә, файдалы булырга ашыгыгыз! (С. Җәлал)

19 (1) Укытучы биргән сорауларның кайсысын проблемалы сорау дип саныйсыз:

1. Текстта язучы образы һәм хикәяләүче белән тәңгәл киләме?
2. Автор нинди символик образлар куллана?
3. Үзеңә җаваплылык алып башкаларга игелек кылу һәрвакыт үзен аклыймы?
4. Текстта нәрсә турында сүз бара?

20 (2) Укытучының: “Без һәрвакыт башкаларга игелек кылуны беренчел дип санарга тиеш” — дигән дәлиленә бер укучы: “Юк, һәрвакыт алай мөмкин түгел,” — дип җавап бирә. Укучыларның бер төркеме аның белән килешүен белдерә. Укытучы бу очракта ни эшли:

1. Укучыны һәм теләктәшлек белдерүчеләрне бик каты кисәтә, алга таба бу фикерне исәпкә алмый гына дәресне дәвам итә.
2. Килеп туган каршылыклы фикердән проблемалы мәсьәлә тудырып аны уртага салып хәл итә һәм нәтиҗә ясыйлар.
3. Укучының хаксызлыгын бик күп мисаллар белән дәлилли, иптәшләреннән дә бу фикернең хата булуын дәлилләтә. Дәресен бу фикернең хата булуын раслауга багышлый.

21 (3) Алда тасвирлаган ситуацияне хәл итү өчен проблемалы сорау тәкъдим итегез. Аның дәрес барышына тиешле юнәлеш бирерлек булуын дәлилләгез.

V.
Бүлек 1. Предмет компетенциясе
Бүлек 1.1. Татар теле

1. [д] авазы:

☐ кече тел, ярымйомык,яңгырау, борын авазы
☐ ирен-теш, саңгырау, шаулы, авыз авазы
☐ тел уртасы, өрелмәле, яңгырау, авыз авазы
☐ тел алды, йомык, шаулы, яңгырау, авыз авазы

2. *Аз — әз, акрын — әкрен, әни — ана* сүзләре туры килгән очракны күрсәтегез

☐ сингармоник параллельләр
☐ фонема вариантлары
☐ диалекталь сүзләр
☐ авазлар чиратлашуы

3. Сүзнең морфемаларга дөрес бүленешен чагылдырган рәтне билгеләгез

☐ авыл-даш-лары-бызга
☐ авылдаш-лар-ы-быз-га
☐ авыл-даш-лар-ыбыз-га
☐ авылдаш-лар-ыбыз-га

4. Бирелгән фигыльләрнең юнәлешен билгеләгез

юыл, сайлан, башлан, киел, карал.

☐ йөкләтү юнәлеше
☐ төшем юнәлеше
☐ кайтым юнәлеше
☐ уртаклык юнәлеше

5. Җөмләнең төрен билгеләгез

Халкыбыз тик нәрсә чәчсә, без шуны урдык кына... (Ш.Бабич)

☐ иярчен тәмамлык җөмлә
☐ иярчен шарт җөмлә
☐ иярчен күләм
☐ иярчен ия җөмлә

6. Үзенчәлекләреннән чыгып, кайсы стиль турында сүз барганлыкны билгеләгез

Әдәби телнең нигезен тәшкил итә (башка стильләргә караганда күбрәк кулланыла). Әдәби стильдәге әсәрләрдә кулланылучы сүз, сүзтезмә һәм җөмләләр эстетик хис тәрбиялиләр

(матурлык тойгысы уяталар), һәртөрле сурәтләү чаралары (эпитет, метафора, чагыштыру, гипербола һ.б.) күбрәк кулланыла, персонажларның кара-каршы сөйләшүләре (диалог) кулланыла, халык авыз иҗаты әсәр тукымасына кертелә, аерым персонажларның тел үзенчәлекләренә урын бирелә (диалекталь, һөнәрчелек һ.б.ш. сүзләр кулланыла).

☐ рәсми стиль
☐ публицистик стиль
☐ фәнни стиль
☐ матур әдәбият стиле

7. Кайсы сүзтезмәдә стилистик хата бар?

☐ зур уңышлар
☐ мәшәкатьле көн
☐ тулы аншлаг
☐ матур көн

1.2. Татар әдәбияты

8. Мәгърифәтчелек реализмына хас билгене күрсәтегез:

1. гади кеше тормышын сурәтләүне генә максат итә.
2. әсәр геройлары бары зыялы кешеләр генә була
3. җәмгыятьне үзгәртеп кору, алга үстерүнең төп шарты итеп кешенең аңын һәм әхлагын үстерне саный
4. әсәрләрдә психологизм өстенлек итә

Җавап_____

10. Һәр әсәрне үзе караган әдәби төр белән парлаштырыгыз:

1. Эпик	А. Г.Бәширов “Җидегән чишмә”
2. Драма	Ә. К. Гали. “Кыйссаи Йосыф”
3. Лирик	Б. Ф. Әмирхан. “Яшьләр”
4. Лиро-эпик	В. Н. Арсланов “Халкыма”

Җавап_____

11. Иҗат юнәлешләрен аерып күрсәтегез:

1. Реализм. 2. Футуризм. 3. Романтизм. 4. Сәяхатнамә. 5. Модернизм. 6. Гуманизм.

Җавап_____

12. Г. Кутуйның “Сагыну” әсәре:

1. лиро-эпик поэма.
2. нәсер.
3. очерк.
4. хикәя.

Җавап_____

13. Төшенчәләр һәм аңлатмалар арасында дөрес тәңгәллек урнаштырыгыз

А. Силлабик шигырь	1. буыннары төшеп калу яки өстәлү сәбәпле төрле ритмик үлчәмдә була.
Ә. Ак шигырь	2.тезмәдә иҗекләр саны тигезлеге ритм тудырудан барлыкка килә.
Б. Интонацион шигырь	3. рифмасыз тезмәләрдән төзелгән шигырь

Җавап_____

14. Тәнкыйди реализм методы белән иҗат ителгән әсәрне билгеләгез
1. Г. Камал. Банкрот.
2. Г. Әпсәләмов. “Алтын йолдыз”
3. Г. Бәширов. “Сиваш”
4. Н. Гыйматдинова. “Ак торна каргышы”
Җавап_____

15. Хатын-кыз язмышын гәүдәләндергән әсәрне билгеләгез
1. Г. Әпсәләмов.“Алтын йолдыз”
2. С.Рәмиев. “Таң вакыты”
3. Г. Ибраһимов. “Татар хатыны ниләр күрми”.
4. Р.Фәйзуллин. “Сәйдәш”
Җавап_____

Бүлек 2. Методик компетенция
Бүлек 2.1. Татар телен укыту методикасы

16 (1)

Татар теле грамматикасын укыту методикасының мөһим мәсьәләләренең берсе — татар телендә ярдәмлек сүз төркемнәренең мөстәкыйль сүзләрдән аермасын табарга өйрәтү. Әлеге грамматик очракның асылын аңлатыгыз, мисаллар ярдәмендә нигезләгез.

17. (2)
Яңа белем бирүдә яки аны ныгытуда түбәндәге бирем кулланыла ала: “Алда китерелгән сүзләр төркеменең берсендә сүз төркемнәрен билгеләүдә хата җибәрелгән, шуны табыгыз, кагыйдә ярдәмендә дәлилләгез”.

Сүзләр:

1) ал, нур, сөйли, дус, карап — *мөстәкыйль сүзләр генә бирелгән;*

2) турында, яз, кышкы, җырлап — *мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүзләр бирелгән;*

3) бакчачы, язгы, белән, алтын — *мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүзләр бирелгән;*

4) сыман, көндез, зур, бала — *мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүзләр бирелгән;*

5) димәк, икән, яки, мул - *ярдәмлек сүзләр генә бирелгән;*

6) җырчы, көйсез, алга, матурлык - *мөстәкыйль сүзләр генә бирелгән.*

Найдите правильный ответ и обоснуйте, укажите на типичные ошибки ученика при выполнении данного задания.

Дөрес җавапны әйтегез һәм дәлилләгез. Укучының әлеге биремне чишкәндә күзәтелә торган типик хаталары нинди?

18 (3).

Татар теле грамматикасын укыту методикасына һәм принципларына нигезләнеп, заманча укыту технологияләрен һәм системалы-эшчәнлекле юнәлешне кулланып, шулай ук укучыларның әзерлек дәрәҗәсен, индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләрен истә тотып, сез татар телендә ярдәмлек сүз төркемнәренең мөстәкыйль сүзләрдән аермасы турында белемнәрне балаларга ничек җиткерерсез?

2.2 Әдәбиятны укыту методикасы

(В отрывке описывается осенний пейзаж и ставится параллель между психологическим состоянием героев и осенью)

Менә бердән икесе дә туктадылар. Көтелмәгән бер киртәгә терәлгән кебек туктадылар да берсенә берсе караштылар. Алларында зур бер агач сап-сары яфракларга сарылып, һаваланып утыра иде. Аның төбендә кечкенә генә итеп төшкән яр астында су борылып-борылып китә, борылганда әллә нигә эләгеп китеп, шырлап- шырлап, көйләп ага иде. Суның теге ягында озын киң ялан, ямь-яшел чикләвеккә батып, иртәнге чык бөртекләре берлә коя-шка каршы җемелдәп-җемелдәп уйный иде. Аның артында зур урман, башыннан аягына кадәр яшелгә бөркәнгән чыршы берлә шалтыраган тавыш чыгара торган сары яфраклар берлә бизәлгән усак. Бу төсләр бер генә түгел, йөз генә түгел, меңләп-меңләп берсе арасына берсе кереп, озын-озын, зур-зур аклы-сарылы бер букет ясыйлар, берсен берсе куа торган төрле киемдәге кешеләр кебек, берсеннән берсе узышып ераккa-ераккa китәләр иде. Доктор да, Гөлсем дә шул манзара астында изелгән кебек катып калганнар иде. Күзләрен ераккa таба теккәннәр дә калганнар иде, икесенең дә күз алдында элгәреге көннәр үтә иде. Элгәреге татлы өметләр, тәмле хыяллар, манзаралар кичә иде. Әнә бу җирдә алар икәү генә балыкка килгәннәр иде. Гөлсем алсурак бер күлмәктән, чәчләре бераз

тузгыган көенчә, шул ярга утырган иде. Әнә теге таштан битләре янган тап-таза егет Хәлил икенче кармакны суга салган иде. Хәлил Гөлсемнең күзенә бик мәгънәле иттереп карады, балаларны күздән кичерде: «Инде көз булды, Гөлсем туташ, көз; һәр агачның җимеше пеште, миләшнеке миләшчә, алманыкы алмача!»—диде... Күзенә яшь тыгылды. Шуны куәтләгән кебек, урман өстеннән бер җил үтте. Агач ботаклары берсенә берсе бәрелде. Бик күп сары яфрак Гөлсемне каплады. (Г. Исхакый)

21 (3).

Алда тасвирлаган ситуацияне хәл итү өчен проблемалы сорау тәкъдим итегез. Аның дәрес барышына тиешле юнәлеш бирерлек булуын дәлилләгез.

19 (1)

Укытучы биргән сорауларның кайсысын проблемалы сорау дип саныйсыз:

1.Текстта көз символы нәрсә белдерә?

2. “Инде көз булды, Гөлсем туташ, көз; һәр агачның җимеше пеште, миләшнеке миләшчә, алманыкы алмача!» дигән җөмләне ничек аңлыйсыз?

3. Һәркем үз язмышына үзе хуҗа. Сез бу фикер белән килешәсезме?

4. Әсәрнең авторын һәм исемен атагыз?

20 (2)

Укытучының: “Һәркемнең язмышы ул кылган гамәлләргә бәйле”— дигән соравына бер укучы: “Юк, һәрвакыт алай була алмый. Гамәл кылырга аерым хәлләр этәрә” — дип җавап бирә. Укучыларның бер төркеме аның белән килешүен белдерә. Укытучы бу очракта ни эшли:

1. Укучыны һәм теләктәшлек белдерүчеләрне бик каты кисәтә, алга таба бу фикерне исәпкә алмый гына дәресне дәвам итә.

2. Укучының хаксызлыгын бик күп мисаллар белән дәлилли, иптәшләреннән дә бу фикернең хата булуын дәлилләтә. Дәресен бу фикернең хата булуын раслауга багышлый.

3. Килеп туган каршылыклы фикердән проблемалы мәсьәлә тудырып аны уртага салып хәл итә һәм нәтиҗә ясыйлар.

21 (3)

Алда тасвирлаган ситуацияне хәл итү өчен проблемалы сорау тәкъдим итегез. Аның дәрес барышына тиешле юнәлеш бирерлек булуын дәлилләгез.

ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ
ПРЕДМЕТ ҺӘМ МЕТОДИКА ӨЛКӘСЕНДӘГЕ
КОМПЕТЕНЦИЯЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ӨЧЕН БИРЕМНӘР

Техническое редактирование:
Гиниятуллина Р. С., Некратова А. В.
Дизайн обложки Шайхутдинова Д.
Форм. бум. 60x84 1/16. Гарнитура SchoolBook.
Усл. печ. л. 1,8

Институт развития образования Республики Татарстан
420015, г. Казань, Б. Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
E-mail: irort2011@gmail.com

Уважаемые коллеги, приглашаем к сотрудничеству!

СОВРЕМЕННОЕ ОБРАЗОВАНИЕ: АКТУАЛЬНЫЕ ВОПРОСЫ И ИННОВАЦИИ

Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77-74813

(выдано Федеральной службой по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций)



Территория распространения:
Российская Федерация и зарубежные страны
Периодичность: четыре раза в год
Опубликованные материалы будут размещены в Научной электронной библиотеке (**e-library.ru**) и войдут в базу данных **Российского индекса научного цитирования (РИНЦ)**
Контактное лицо: Шайхутдинова Галия Айратовна
Адрес электронной почты: smi@irort.ru

Подробная информация для авторов http://irortsmi.ru/node/3

АКТУАЛЬНАЯ ПЕДАГОГИКА



Территория распространения:
Российская Федерация и зарубежные страны
Свидетельство о регистрации: ПИ №ФС77-75641 от 26 апреля 2019 г.
Материалы публикуются на русском и татарском языках
Контактное лицо: Абдулаев Валерий Анатольевич
Номер телефона редакции: 8 937610 37 60
Адрес электронной почты: vabdulaev@inbox.ru







Институт развития образования
Республики Татарстан
420015, Казань, Большая Красная, 68
(843) 236-65-63, 236-62-42
irort2011@gmail.com